**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Сукаеш авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Зур Сукаеш авылы № 26 24 ноябрь 2017 ел

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Сукаеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл Советы карары проекты хакында

Җирле үзидарә турында федераль һәм республика законнарындагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә

Сукаеш авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Сукаеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Карары проектын (1 нче кушымта) кабул итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча: http://aznakyevo.tatarstan.ru, Сукаеш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында 27.11.2017 елдан да соңга калмыйча.

3. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Сукаеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Сукаеш авыл җирлеге карары проекты буенча 18.12.2017 елда 16.00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча ачык тыңлаулар үткәрергә: Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Зур Сукаеш авылы, Совет ур., 34 йорт.

4. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Сукаеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелергә мөмкин: Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Зур Сукаеш авылы, Мәктәп урамы, 4-2 йорт.

5. Гавами тыңлаулар уздыру буенча составта эшче төркем төзергә:
- Закирова З.Җ. - Сукаеш авыл җирлеге башлыгы;
- Фәхретдинов Ф.Ф. - Сукаеш авыл җирлеге депутаты;
- Вәлиева Л. М. - Сукаеш авыл җирлеге депутаты

6. Гавами тыңлаулар уздыру буенча эшче төркемгә «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Сукаеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»карар проекты буенча гавами тыңлаулар уздыруны, гражданнарның тәкъдимнәрен кабул итүне, исәпкә алуны тәэмин итәргә

7. Законлылык һәм хокук тәртибе мәсьәләләре буенча даими комиссиягә гавами тыңлауларда әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм чираттагы утырышка карауга кертергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Закирова З.Җ..